**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№18 Кәрәкәшле ав. 2019 ел 28 октябрь

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге “Җир салымы турында”гы № 21 карарына үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 27 апрелендәге №11 санлы, 2015 елның 22 маендагы №13, 2015 елның 15 октябрендәге № 8 санлы редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының II өлеше 31 бүлегенең 387 нче маддәсе һәм 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1 маддә.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 22 номерлы «Җир салымы турында» карарына (2015 елның 27 апрелендәге №11 санлы, 2015 елның 22 маендагы №13, 2015 елның 15 октябрендәге № 8 санлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1."Салым ставкалары" дигән 2 маддәнең 1 пунктында:

3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен булдырылган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләргә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге " Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - 0,15%.";

5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Торак фонды биләгән җирләргә карата (торак фондына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) – 0,25 %;

6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләргә карата - 0,25%.

2. «Салым түләү тәртибе һәм сроклары» дигән 5 маддәне төшереп калдырырга.

2 маддә .

Әлеге карарның 1 пункты - 2020 елның 1 гыйнварыннан , 2 пункты - 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: Г.М.Хәмидуллина